ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 4 14.03.2024 ел

*2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 5 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 5 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында*

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Уставының 22 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 25 мартында 11 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Малиновка торак пункты, Болын урамы, 3 санлы йорт адресы буенча урнашкан торак йорт бинасы янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында 2023 елның 22 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 5 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 5 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез эшләнәсе эшләрне түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 5 санлы, 2023 елның 22 нгоябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 5 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертүгә сез ризамы:

«1) Малиновка торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (зират территориясендәге коймаларны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү));

2) Малиновка торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://yutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (реер//pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар аның игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина